КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 июнь г.Казань № 521

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 22 сентябрь, 819 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 22 сентябрь, 819 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 19 апрель, 314 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле гомумхуҗалык ихтыяҗлары норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларында:

4 пунктның 4.3 пунктчасында «1,50» саннарын «1,47» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган стационар һәм ярымстационар формалы социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмаларында койка-көннәр һәм койка-урыннар санында:

«Кукмара муниципаль районы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Кукмара муниципаль районы | «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Мило- | 4 478 | 7 836 | 346 | 11 | 34 | 1». |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | сердие» тернәкләндерү үзәге» ДАСХКУ | | | | | | |

2. Бу карар 2019 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин